| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ШАРЛИАРЕМИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>САРМАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>САРМАН<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ШӘРЛӘРӘМӘ АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

ПОСТАНОВЛЕНИЕ № 5 КАРАР

1 ноябрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә авылында 2025 елга үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьялары, 18.1 статьясы Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Шәрләрәмә авыл җирлеге Уставы нигезендә:

1.Шәрләрәмә авылы мәдәният йорты бинасында, Шәрләрәмә авылы, Мәктәп урамы, 57 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын 2024 елның 20 ноябренә 10 сәгать 00 минутта билгеләргә.

2.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Шәрләрәмә авыл җирлеге Шәрләрәмә авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, I төркем инвалидларыннаннан, көндезге уку йортлары студентларыннан һәм армия сафларында хезмәт итучеләрдән тыш, 2025 елда 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә килешәсезме?:

- Шәрләрәмә авылы зиратында биек агачларны кису;
1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Беларусь МТЗ 82.1 тракторына ГСМ сатып алу; Беларусь МТЗ 82.1 тракторы өчен запас частьләр сатып алу, Елга урамында биек агачларны кису);
2. Шәрләрәмә торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (юлларны кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);) юлларны вак таш белән каплауны оештыру(вак таш ташу);»

«ӘЙЕ»ЮК".

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» урнаштырырга. PRAVO.TATARSTAN.RU («Сарман муниципаль районы»

муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында) һәм «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә, Шәрләрәмә авылы территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында.

4. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шәрләрәмә авыл җирлеге башлыгы
Сарман муниципаль районы башлыгы Н.Н.Хуҗина